**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чубар-Абдул авылы № 138 03 март 2015 ел.

Чубар-Абдул авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгының 27 февраль 2015 елда чыккан 5номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 3 март 2015 елда чыккан 137 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Чубар-Абдул авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 19 апрель 2015 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   "Сез, Чубар-Абдул авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2015 елда 200 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узара салым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   - Авыл җирлеге биләмәсен төзекләндерү;
   - Авыл җирлеге биләмәләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.

   "ӘЙЕ" "ЮК"
3. Карар районның "Маяк" газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: Н.А. Фатхетдинов